РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Исполнительный комитет Янгасалского сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Янасала авыл жирлеге башкарма комитеты**

ул. Центральная, 1, с.Большая Янгасала, 422832
тел. (8277) 3-55-22 факс: (8277) 3-55-22

ОКПО 93064624 ОГРН 1061672003414
ИНН/КПП 1622004588/162201001

Центральная урамы, 1,Янасала авылы, 422832,
тел. (8277) 3-55-22 факс: (8277) 3-55-22

ОКПО 93064624 ОГРН 1061672003414
ИНН/КПП 1622004588/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2023 елның 23 мае** **№ 3**

**Хуҗасыз хайваннарны кайтару тыелган урыннарны билгеләү һәм хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итәргә вәкаләтле затлар исемлеге турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы федераль законнарга ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы ассоциациясенең» 2023 елнын 26 апрелендэге №409 хаты нигезендэ, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының "Яңасала авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган түбәндәге урыннарны билгеләргә:

ФАП территориясе;
Мәдәният йортлары территорияләре;
Мәчет территориясе
Балалар мәйданчыклары территориясе;
Мәктәп территориясе;
Балалар бакчасы территориясе;
Парк территориясе;

Ял зоналары территорияләре.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы Шиһабеев Исфан Хәкимулла улын хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карарлар кабул итүче вәкаләтле зат итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Яңасала авылы, Үзәк ур., 1;

2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Шәпкә авылы, Клуб урамы, 14 , Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (kamskoye-ustye.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан коненнэн үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Х.Шиһабеев